**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Дубъязы, ул. Ленина, 28

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Дөбъяз авылы, Ленин ур., 28

Тел./факс: +7(84365) 61-2-97, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**07 сентябрь, 2021 ел** **№ 34**

**Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 ноябрендәге 140 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2021 елның 30 апрелендәге 116-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлеге Советы,

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Дөбъяз авыл җирлеге Советының 2019 елның 20 ноябрендәге 140 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Дөбъяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәгә (Советның 13.02.2020 №157, 09.12.2020 №11 карарлары редакциясендә), 6 статьясындагы 1 өлешнең 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләте гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил дәүләте территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган яшәүгә рөхсәт яисә башка документ булу;».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Совет рәисе ур.,
Авыл җирлеге башлыгы ур. И.Ф.Бариев